**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 1** **20 ноябрь 2019 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге составына керүче Карамалы-Елга авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 20 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:

«Сез, 2020 елда Түйкә авыл җирлеге Карамалы-Елга торак пункты территориясендә 1 Төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 (Бер мен) сум күләмендә, 2 группа инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр өчен 500 (Биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

-Карамалы – Елга авылы зират коймасын алмаштыру (материаллар сатып алу, эшләр өчен килешү буенча түләү);

- Карамалы-Елга авылы Сәйдәшев урамы исеме язылган күрсәткечләр сатып алу;

- Карамалы-Елга авылы юлларын кардан чистарту;

- үзәкләштерелгән чыганаклардан эчә торган суны анализлау: “Карамал башы" чишмәсе;

- Карамалы-Елга авылында «Авыл бәйрәме»н үткәрү буенча хезмәт күрсәтү, бүләк, сувенир продукциясе сатып алу;

- Карамалы-Елга авылы Сәйдәшев урамы юлынын техник паспортын ясату;

- Карамалы-Елга авылы зиратынын җир кишәрлеген ызанлау; җирләрнең категорияләрен үзгәртү;

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда, сайлау хокукына ия булучы катнашучылар исемлегендә 46 кеше теркәлгән, җыенда тавыш бирүдә катнашучылар саны - 29 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашучы 29 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчең җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар чыгарды:

1. Азнакай муниципаль районы Туйкә авыл җирлеге составына керүче Карамалы-Елга авылында узган халык җыенын узган, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул итәргә: « Сез, 2020 елда Түйкә авыл җирлеге Карамалы-Елга торак пункты территориясендә 1 Төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 (Бер мен) сум күләмендә, 2 группа инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр өчен 500 (Биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

-Карамалы – Елга авылы зират коймасын алмаштыру (материаллар сатып алу, эшләр өчен килешү буенча түләү);

- Карамалы-Елга авылы Сәйдәшев урамы исеме язылган күрсәткечләр сатып алу;

- Карамалы-Елга авылы юлларын кардан чистарту;

- үзәкләштерелгән чыганаклардан эчә торган суны анализлау: “Карамал башы " чишмәсе;

- Карамалы-Елга авылында «Авыл бәйрәме»н үткәрү буенча хезмәт күрсәтү, бүләк, сувенир продукциясе сатып алу;

- Карамалы-Елга авылы Сәйдәшев урамы юлынын техник паспортын ясату;

- Карамалы-Елга авылы зиратынын җир кишәрлеген ызанлау; җирләрнең категорияләрен үзгәртү”.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

ТР, Азнакай муниципаль районы, Түйкә авылы, Җәлил ур.,19 йорт;

ТР, Азнакай муниципаль районы, Түйкә авылы Гагарин ур., 4а йорт;

ТР, Азнакай муниципаль районы, Карамалы-Елга ур., Сәйдәшев ур., № 19а йорт янында.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Туйкә авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Туйкә авыл җирлеге Башлыгы Закирова Р.Р.